# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 28 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

"Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында" 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 6, № 9 – 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Түбәндәгеләргә салым ставкасын 5 процент күләмендә билгеләргә:

1) тиешле хисап (салым) чорына керемнең кимендә 70 процентын икътисадый эшчәнлекнең түбәндәге төрләрен гамәлгә ашырудан керем тәшкил иткән салым түләүчеләр өчен:

а) эшкәртү җитештерүе;

б) электр энергиясе, газ һәм су җитештерү һәм бүлү;

в) төзелеш;

2) 2011 елның 1 гыйнварыннан 2013 елның 1 июленә кадәр эксплуатациягә кертелгән, техник документация буенча машина урыны саны кимендә 150 берәмлек булган автомототранспорт чараларын куеп торуның күпкатлы һәм җир асты урыннарында (парковкаларда) автомототранспорт чараларына куеп тору урыннары (парковкалар) хезмәте күрсәтүләрдән керем тиешле хисап (салым) чорына керемнең 100 процентын тәшкил иткән салым түләүчеләр өчен.";

2) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**"2 статья**

Түбәндәгеләрнең үз көчен югалтуын танырга:

1) 2013 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 1 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктының һәм 3 өлешенең;

2) 2026 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 1 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктының.".

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының җиденче абзацы нигезләмәсе 2011 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 8 мае
№ 15-ТРЗ